КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 июнь г.Казань № 750

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 ел, 8 май, 287 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 ел, 8 май, 287 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 19 май, 388 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1040 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 март, 195 нче; 2012 ел, 10 октябрь, 844 нче; 2013 ел, 19 март, 193 нче; 2013 ел, 18 июль, 501 нче; 2013 ел, 22 август, 592 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 859 нчы; 2014 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы; 2014 ел, 22 октябрь, 773 нче; 2015 ел, 11 июнь, 426 нчы; 2017 ел, 16 март, 148 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1072 нче; 2018 ел, 8 август, 643 нче; 2018 ел, 29 октябрь, 952 нче; 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче; 2019 ел, 29 апрель, 359 нчы; 2019 ел, 6 сентябрь, 797 нче; 2019 ел, 25 октябрь, 957 нче; 2020 ел, 31 гыйнвар, 62 нче; 2020 ел, 11 февраль, 98 нче; 2020 ел, 12 май, 381 нче; 2020 ел, 3 июнь, 464 нче; 2020 ел, 3 сентябрь, 781 нче; 2021 ел, 26 гыйнвар, 25 нче; 2021 ел, 20 июль, 608 нче; 2021 ел, 12 октябрь, 970 нче, 2022 ел, 19 май, 474 нче, 2022 ел, 03 август, 753 нче, 2023 ел, 03 февраль, 91 нче, 2023 ел, 22 март, 320 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасы һәм структурасы турында» 2023 елның 4 маендагы 276 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2008 елның 31 декабрендәге ПУ--713 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктта:

җиденче абзацта «ведомство» сүзен төшереп калдырырга;

тугызынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итү системасы турында» 2023 ел, 30 май, 655 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итү системасы турындагы нигезләмә нигезендә мәгариф һәм фән өлкәсендә дәүләт программасын җаваплы башкаручы булып тора;»;

утыз беренче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

утыз дүртенче абзацта «дәүләт аккредитациясе булган һәм гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында белем бирү процессында файдалануга кертелгән дәреслекләрнең федераль исемлеге» сүзләрен «белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан башлангыч дәүләт аккредитациясе булгангомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда файдалануга кертелгән дәреслекләрнең федераль исемлеге» сүзләренә алмаштырырга;

утыз алтынчы һәм утыз җиденче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) үзәкләштерелгән билгеләүне оештыру һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларының үз көчләрен югалтуын тану мәсьәләләре турында» 2008 ел, 28 август, 615 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы заказчылары ихтыяҗлары өчен заказ бирелә торган хезмәтләрнең үзәкләштерелгән сатып алына торган товарлар исемлеге буенча заказ урнаштырудан тыш, Министрлык буйсынуындагы оешмалар заказчылары өчен заказлар урнаштыру функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булып тора»;

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә заказчы исеменнән эш итәргә хокукы булган затның көчәйтелгән электрон имзасы белән имзалый һәм бердәм мәгълүмат системасында һәм электрон мәйданчыкта (бердәм мәгълүмат системасыннан файдаланып) контракт урнаштыра (Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очраклардан тыш);»;

кырык җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

җитмеш беренче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органына» сүзләренә алмаштырырга;

туксанынчы абзацта «ведомство» сүзен төшереп калдырырга;

3.5 пунктта:

өченче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

4.2 пунктта:

алтынчы абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «ведомство» сүзен «тармак» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин